«Раслыйм»
«Сэлэт» ТРЯИФ
Генераль директоры
_____________ Җ.Ш. Сөләйманов
“____”_____________ 2016

**Флүс Латыйфи исемендәге «Сәләткә нур булган йолдызлар»**
**V ачык әдәби ярышын үткәрү**

# НИГЕЗЛӘМӘСЕ

## 1. Ярышны оештыручылар

Флүс Латыйфи исемендәге «Сәләткә нур булган йолдызлар» ачык әдәби ярышы (алга таба – Ярыш) әдәби, сәяси-иҗтимагый «Идел» яшьләр журналы, «Ялкын» яшьләр журналы, «Салават күпере» балалар журналы, «Таттелеком» акционерлык җәмгыяте белән берлектә Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы «Сэлэт» иҗтимагый фонды, «Сэлэт» яшьләр үзәге тарафыннан оештырыла.

## 2. Ярышның максатлары

Ярыш үз алдына түбәндәге максатларны куя һәм тормышка ашыра:

– әдәбият өлкәсендә сәләтле булган балаларны һәм яшьләрне барлау, аларга иҗади яктан үсүдә ярдәм күрсәтү;

– балаларда һәм яшьләрдә эстетик зәвыкъ һәм әдәби мәдәнияткә мәхәббәт тәрбияләү;

– сәләтле яшь язучыларның игътибарын хәзерге заман татар әдәбиятына һәм татар халкының рухи мирасына юнәлдерү;

– язучы һәм «Сәләт» оешмасы катнашучыларының остазы Флүс Латыйфиның исемен “Сәләт” моһитендә яңгырату һәм яшәтү;

– татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайны искә алу;

– сәләтле яшьләрне «Сәләт» оешмасының проекталрына чакыру.

**3. Ярышның номинацияләре**

Ярыш түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

– шигърият;

– чәчмә әсәр;

– мәкалә;

– балалар әдәбияты;

– драматургия.

Ярыш Габдулла Тукай тууының 130-еллыгына багышлана һәм бу уңайдан махсус номинация дә үткәрелә:

– «Тукайга хат» темасына эссе.

**4. Ярышның казыйлар шурасы**

4.1 Ярышның казыйлар шурасына Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзалары, танылган шагыйрьләр һәм прозаиклар, күренекле журналистлар һәм мәдәният эшлеклеләре керә.

4.2 Катнашучыларның иҗади эшләренә казыйлар түбәндәге критерийләр буенча бәяләмә бирәчәк (5 баллы система буенча):

- үзенчәлек, идея яңалыгы;

- язманың иҗади кыйммәте;

- фикер тирәнлеге.

**5. Ярышның катнашучылары**

5.1 Ярышта 12 яшьтән алып 22 яшькә кадәр сәләтле мәктәп балалары һәм белем бирү оешмалары студентлары катнаша ала.

5.2 Ярыш түбәндәге яшь категорияләре буенчы үткәрелә:

– 12-14 яшь;

– 15-18 яшь;

– 19-22 яшь.

**6. Ярышның катнашучыларның эшләренә карата куелган шартлар**

6.1 Ярышка иҗади эшләр түбәндәге күләмдә кабул ителә:

– шигърият – 3 язмадан күбрәк булмаска тиеш;

– чәчмә әсәр – 3 язмадан күбрәк булмаска тиеш;

– мәкалә – 2 язмадан күбрәк булмаска тиеш;

– балалар әдәбияты – 2 язмадан күбрәк булмаска тиеш;

– драматургия – 3 язмадан күбрәк булмаска тиеш;

– «Тукайга хат» темасына эссе – 1 язмадан күбрәк булмаска тиеш.

6.2 Ярышка иҗади эшләр татар телендә кабул ителә.

6.3 Иҗади эшләр өчен авторлар үзләре җавап бирә.

6.4 Ярышка кабул ителенгән иҗади эшләр кире кайтарылмый.

6.5 Ярышта катнашу өчен гаризалар «Сәләт» оешмасының рәсми сайтында www.selet.biz кабул итеп алына.

6.6 Ярышта катнашучы берничә номинациядә көч сынашырга теләсә, аңа тиешле санда гариза тутырырга кирәк.

6.7 Конкурс эшләре selet.nur@gmail.com адресы буенча электрон почтага кабул итеп алына.

6.7.1 Хатның темасы түбәндәгечә күрсәтелә: Номинация – катнашучының фамилиясе (тулысынча), исеме һәм әтисенең исеме (инициаллары).

6.8 Конкурс эшләре түбәндәге шартларга туры китереп языла:

– шрифт: Times New Roman;

– шрифтның зурлыгы: 14;

– юлара интервал: 1,5;

– әгәр иҗади эш шигырь формасында булса, текст битнең сул ягы буенча тигезләнә; әгәр иҗади эш проза формасында булса, текс бит киңлеге буенча тигезләнә;

– язманың исеме уртада ярымкалын шрифт белән күрсәтелә.

6.8 Конкурс эшенең титул бите түбәндәге пунктлардан гыйбарәт:

– катнашучының исем-фамилиясе, әтисенең исеме (тулысынча);

– номинация;

– катнашучының тулы яше;

– катнашучының уку урыны, сыйныфы (курсы);
– җитәкченең исем-фамилиясе, әтисенең исеме (тулысынча) һәм вазыйфасы.

6.9 Оештыру комитеты ярышка кабул ителгән эшләрне төрле матбугат чараларында бастырырга хокуклы.

**7. Ярышның үткәрелү вакыты һәм үткәрелү урыны**

«Сәләткә нур булган йолдызлар» ярышы өч этапта үткәрелә:
– 1-нче этап – 29-нчы февраль – 31-нче март – читтән торып гаризаларны кабул итү этабы;
– 2-нче этап – 1-нче апрель – 15-нче апрель – ярышка кабул ителгән эшләрне казыйлар шурасы тарафыннан бәяләү этабы;
– 3-нче этап – ярышның финалы Казанда «Сәләт» йортында булачак. Финалның үткәрелү көне алдан хәбәр ителәчәк.

**8. Ярышны оештыру комитетының контактлары**

Ярышны оештыру комитеты «Сәләт» йортында (Казан, Островский ур., 23-нче йорт) урнашкан. Белешмәләр өчен телефон: 8-939-730-41-34. E-mail: selet.nur@gmail.com. «Сәләт» оешмасының рәсми сайты: www.selet.biz. «ВКонтакте» социаль челтәрендә ярышның рәсми төркеме: vk.com/selet-nur.